**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Балаларның һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәте белән хезмәттәшлек буенча Татарстан Республикасы Рәисе карамагындагы республика координация советы составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Рәисенең «Балаларның һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәте белән хезмәттәшлек буенча Татарстан Республикасы Рәисе карамагындагы республика координация советын төзү турында» 2023 елның 13 февралендәге 90 номерлы Указы нигезендә (Татарстан Республикасы Рәисенең 2025 елның 14 мартындагы 198 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Балаларның һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәте белән хезмәттәшлек буенча Татарстан Республикасы Рәисе карамагындагы республика координация советы (алга таба – Координация советы) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Координация советы составыннан З.Р. Вәлиеваны, И.В. Волынецны, Р.Н. Садыйковны чыгарырга;

б) Координация советы составына түбәндәгеләрне кертергә:

Захарова Светлана Михайловнаны – Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне (килешү буенча);

Координация советы секретаре итеп раслап, Кадыйров Азат Рифгать улын – Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрын;

Терентьев Александр Михайловичны – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен (килешү буенча);

в) Координация советы әгъзасы Р.Б. Зариповның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, яшьләр сәясәте, спорт һәм туристлык идарәсе башлыгы».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2026 ел, 20 март
№ 216